КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1352

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәллərдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге турындагы нигезләмәне, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелегенең төп һәм индикатив күрсәткечләрен, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары исемлеген һәм аларны ачыклау тәртибен раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 930 нчы карары белән расланган Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелегенең төп һәм индикатив күрсәткечләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге турындагы нигезләмәне, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелегенең төп һәм индикатив күрсәткечләрен, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу

рискы индикаторлары исемлеген һәм аларны ачыклау тәртибен раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 930 нчы карары белән расланган Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелегенең төп һәм индикатив күрсәткечләренә, аларны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Бу карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 30 сентябрь, 930 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 30 декабрь, 1352 нче
карары редакциясендә)

## Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелегенең төп һәм индикатив күрсәткечләре

### Төп күрсәткечләр

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Еллар һәм күрсәткечләрнең максатчан (фараз) мәгънәләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел (база мәгънәсе) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
| 1. | 100 мең кешегә гадәттән тыш хәлләрдә һәлак булган кешеләр санын киметү, кеше | 0 | 0,11 | 0,11 | 0,11 |
| 2. | 100 мең кешегә гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән кешеләр санын киметү, кеше | 0,01 | 0,13 | 0,13 | 0,13 |
| 3. | Татарстан Республикасының тулаем төбәк продуктына карата гадәттән тыш хәлләр аркасында салынган матди зыянны киметү, млн.сум | 0 | 0,0003 | 0,0003 | 0,0003 |

### Индикатив күрсәткечләр

1) Хисап чорында план буенча үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
2) хисап чорында планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
3) хисап чорында контрольдә тотылучы объектның мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторларында расланган параметрларга туры килүен яки контрольдә тотылучы объектның мондый параметрлардан читкә китүен ачыклау нигезендә планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
4) хисап чорында хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;

5) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларының һәр төре буенча хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

6) хисап чорында үзара дистанцион хезмәттәшлек итү чараларыннан файдаланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

7) хисап чорында ясалган мәҗбүри профилактик визитлар саны;

8) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында игълан ителгән кисәтүләр саны;

9) хисап чорында нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

10) хисап чорында йомгаклары буенча административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән һәм прокуратура органнары тарафыннан килештерелмәгән гаризалар саны;

14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы объектларның гомуми саны;

15) хисап чоры ахырына исәпкә алынган, риск категорияләренә кертелгән контрольдә тотылучы объектларның риск категорияләрендәге һәрберсе буенча саны;

16) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

17) хисап чорында исәпкә алынган һәм аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән контрольдә тотылучы затлар саны;

18) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

19) хисап чорында контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) орган тарафыннан карап тикшерү срогы бозылган шикаятьләр саны;

20) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән, карап тикшерү йомгаклары буенча контрольдә тотучы органның карарын тулысынча йә өлешчә гамәлдән чыгару турында яисә контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органнарның вазыйфаи затлары гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлдән чыккан дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләр саны;

21) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;

22) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән, белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;

23) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.